СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**21.03.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 476**

Зеленодольск муниципаль районы милкендәге хуҗалык алып бару хокукында я оператив идарә итү хокукында муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибен раслау турында

2006 елның 26 июлендәге «Конкуренцияне яклау турында» 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 3 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары белән расланган Дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата аренда шартнамәләрен конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә төзү кагыйдәләренең 8 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы милкендәге хуҗалык алып бару хокукында я оператив идарә итү хокукында муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы Советының
2025 елның 21 мартындагы
476 номерлы карары белән
расланды

Зеленодольск муниципаль районы милкендәге хуҗалык алып бару хокукында я оператив идарә итү хокукында муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне конкурслар яисә аукционнар уздырмыйча гына арендага тапшыруны килештерү тәртибе

1. Әлеге Тәртип конкурслар яки аукционнар үткәрмичә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе (алга таба- Мәдәният идарәсе) карамагындагы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль бюджет мәдәният учреждениеләренә хуҗалык алып бару хокукында я оператив идарә хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәткә карата төзелә торган аренда шартнамәләре төзүне килештерү процедурасын билгели, (алга таба – Тәртип) түбәндәгеләр белән төзелә торган:

а) мәдәният оешмаларында булучыларны һәм хезмәткәрләрне тукландыруны оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында җәмәгать туклануы оешмалары белән;

б) мәдәният оешмаларына килүчеләрнең ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукция белән ваклап сату мәдәният оешмалары эшчәнлегенең тиешле максатларын оештыру максатларында сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукцияне ваклап сату сәүдәсен гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар белән.

2. Муниципаль бюджет мәдәният учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетелгән Зеленодольск муниципаль районы муниципаль милектәге күчемсез мөлкәт объектларын (алга таба – учреждение мөлкәте) арендага бирү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) белән килештереп башкарыла (мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен һәм учреждениеләрне гамәлгә куючы вәкаләтләрен башкаручы орган).

3. Мәдәният идарәсе аренда шартнамәсе төзү кирәклеге турындагы заявканы карау нәтиҗәләре буенча «Конкуренцияне яклау турында»гы 2006 елның 26 июлендәге 135–ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 3.5 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару йә оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата аренда шартнамәләрен конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә төзү кагыйдәләрен раслау турында»гы 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары нигезендә, Башкарма комитетка мөрәҗәгать итүчегә мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) җибәрә.

4. Мөрәҗәгатьтә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) фаразланучы арендаторның исеме, аның урнашкан урыны турында белешмәләр, почта адресы һәм контакт телефоны номеры;

2) хуҗалык алып бару я оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт турында арендага тапшырырга тәкъдим ителә торган белешмәләр;

3) хуҗалык алып бару я оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне арендага бирү аны нәтиҗәлерәк файдалануга ярдәм итәчәген нигезләү;

4) аренда шартнамәсен төзү тәкъдим ителә торган срок;

5) мөлкәтне конкурс яисә аукцион уздырмыйча гына арендага бирү өчен күздә тотыла торган арендаторны сайлауны хокукый нигезләү:

а) арендаторның мөлкәткә ихтыяҗы, мөлкәттән файдалануның күздә тотыла торган максатлары;

б) муниципаль мәдәният оешмасына килүчеләргә һәм хезмәткәрләренә җәмәгать тукклануы хезмәтләрен күрсәткәндә сату өчен тәкъдим ителә торган продукция һәм товарлар ассортименты турында мәгълүмат-җәмәгать туклануын оештыру өчен;

в) сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукция ассортименты турында мәгълүмат - ваклап сату белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар өчен.

5. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) мөлкәтне арендалау шартнамәсе проекты;

2) бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турында хисап (хисапны төзегән көннән алып алты айдан да артмаган вакыт белән);

3) фаразлана торган арендаторның (җәмәгать туклануын оештыру, сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукция белән ваклап сатуны гамәлгә ашыручы юридик зат яисә индивидуаль эшкуар) гаризасы күчермәсен;

4) шәхесне таныклый торган документның күчермәсе һәм индивидуаль эшкуарлар өчен Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (30 көннән дә артмаган срок белән) - индивидуаль эшкуарлар өчен;

5) юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (30 көннән дә артмаган срок белән) - юридик затлар өчен.

6. Муниципаль мәдәният оешмасына мөлкәтнең бер төрен (төрләрен) арендалауга карата ике һәм аннан күбрәк мөрәҗәгать итүчедән гаризалар кергән очракта, мөрәҗәгать гариза кергән датадан чыгып чират тәртибендә җибәрелә.

7. Башкарма комитет мөрәҗәгатьне һәм аңа кушып бирелгән барлык документларны алар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) мөлкәтне арендага тапшыруны килештерергә;

2)мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тартырга.

8. Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) мөлкәтне арендага бирү муниципаль мәдәният оешмасы эшчәнлеген нәтиҗәлерәк оештыруга китермәячәк;

2) мөлкәтне арендага бирү максатлары муниципаль мәдәният оешмасының уставында каралган эшчәнлек төрләренә туры килми;

3) мөлкәтне арендага бирү элек чиратлылык тәртибендә кергән гаризага карата мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча килештерелгән

9. Кабул ителгән карар Башкарма комитет тарафыннан карар рәвешендә рәсмиләштерелә һәм кабул ителгән көненнән алып 3 көн эчендә муниципаль мәдәният оешмасына җибәрелә.

10. Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турындагы карарда баш тарту сәбәпләрен нигезләү булырга тиеш.

Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар муниципаль мәдәният оешмасына мондый карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә кире кайтарыла.

11. Мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында кабул ителгән карар муниципаль мәдәният оешмасы тарафыннан мөлкәтне конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә арендалау шартнамәсен төзү өчен нигез булып тора

12. Муниципаль мәдәният оешмасы аренда шартнамәсе төзелгән көннән алып 10 көн эчендә мөлкәтне гамәлгә куючыга һәм мөлкәт милекчесенә аренда шартнамәсе төзелү турында язма рәвештә хәбәр итә (арендага бирелгән мөлкәт исемлеге һәм аны арендага бирү срогы кушымтасы белән).